# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Янгын куркынычсызлыгы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. "Янгын куркынычсызлыгы турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы җыелма басмасы, 1993 ел, N 11-12) һәм үзгәрешләр белән кабул ителгән Законына (Татарстан Югары Советы җыелма басмасы, 1994 ел, N 1-2 ) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1 статья. Законның преамбуласын түбәндәгечә бәян итәргә:

"Әлеге Закон Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүнең һәм янгыннан саклануның хокукый нигезләрен билгели".

2 статья. 1 статьяда:

1 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

"1. Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгы янгыннарны булдырмауга һәм аларга каршы көрәшкә юнәлдерелгән хокукый, оештыру, икътисадый һәм фәнни-техник гамәлләр системасыннан гыйбарәт";

2 пунктның 1 өлешен түбәндәгечә бәян итәргә:

"1) янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу";

2 пунктның 3 өлешендә "милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, урындагы затлар һәм гражданнар" дигән сүзләрне "хокукый һәм физик затлар" дигән сүзләргә алмаштырырга.

2 пунктның 5 өлешендә "затларның һәм гражданнарның" дигән сүзләрне "һәм физик затларның" дигән сүзләргә алмаштырырга.

3 статья. 2 статьяны түбәндәгечә бәян итәргә:

"2 статья. Янгын куркынычсызлыгының һәм янгыннан саклануның хокукый нигезләре

Янгын куркынычсызлыгының һәм янгыннан саклануның хокукый нигезен Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары һәм норматив хокукый актлары тәшкил итә".

4 статья. 3 статьяда:

1 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

"1. Янгын куркынычсызлыгының нормалары һәм кагыйдәләре - янгын куркынычсызлыгы дәрәҗәсен тәэмин итә торган таләпләрне билгеләүче норматив документлар";

2 пунктта "милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, урындагы затлар һәм гражданнар" дигән сүзләрне "хокукый һәм физик затлар" дигән сүзләргә алмаштырырга".

5 статья. 4 статьяда:

1 пунктта "министрлыклары" дигән сүздән соң," дәүләт комитетлары" дип өстәргә;

2 пунктның 1 өлешендә "оештыру һәм уздыру" сүзләрен "гамәлгә ашыру" дигән сүзгә алмаштырырга;

2 пунктның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) янгын куркынычсызлыгы турында законнар чыгару өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукы";

2 пунктның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3) янгынга каршы дәүләт хезмәтен камилләштерүнең, торак пунктларның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның янгынга каршы торучанлыгын арттыру буенча төп янгын-техник гамәлләрнең, бу өлкәдә фәнни-техник уңышларга ирешүнең планнарын раслау, шулай ук аларның гамәлгә ашырылуын тикшереп тору";

2 пунктның 4 өлешен төшереп калдырырга;

2 пунктның 5 өлешен 4 өлеш дип исәпләргә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4) янгыннан саклануның тармакара проблемаларын хәл итү буенча министрлыкларның һәм ведомстволарның эшчәнлеген җайга салу";

түбәндәге эчтәлектә 3 пункт өстәргә:

"3. Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча министрлыкларның, дәүләт комитетларының һәм ведомстволарның эшчәнлеген җайга салу һәм камилләштерү максатларында Янгын куркынычсызлыгы буенча Татарстан Республикасының Хөкүмәт комиссиясе төзелә".

6 статья. 5 статьяда "гамәлдәге нормативлар" дигән сүзләрне "янгын куркынычсызлы нормалары һәм кагыйдәләре" дигән сүзләргә алмаштырырга.

7 статья. 2 бүлекнең исемен түбәндәгечә бәян итәргә:

**"2 бүлек. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт хакимияте һәм идарәсе җирле органнарының, җирле үзидарә органнарының, хокукый һәм физик затларның вәкаләтләре".**

8 статья. 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6 статья. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә дәүләт хакимияте һәм идарәсе җирле органнарының, җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре.

1. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә дәүләт хакимиятенең җирле органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге максатчыл программаларны раслау;

2) янгын куркынычсызлыгы, шул исәптән янгыннан саклану хезмәтен тоту чыгымнарының җирле бюджетларын раслау;

3) янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен җирле фондлар һәм хокукый, физик затлардан максатчыл җыемнар барлыкка китерү, җирле фондлар һәм максатчыл җыемнар турындагы нигезләмәләр һәм әлеге акчаларны куллану хакындагы хисапларны раслау;

4) янгынга каршы көрәштә катнашу өчен хокукый һәм физик затларны җәлеп итү тәртибе турында, янгын куркынычсызлыгы гамәлләренә гражданнарны өйрәтү өчен оештыру тәртибе хакында карарлар кабул итү.

2. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә дәүләт идарәсенең җирле органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге максатчыл программаларның проектларын әзерләү;

2) җирле бюджетларның янгын куркынычсызлыгына, шул исәптән янгыннан саклану хезмәтен тоту чыгымнарының проектларын әзерләү;

3) җирле бюджетлар исәбеннән финансланучы янгыннан саклану бүлекчәләрен билгеләнгән тәртиптә төзү, үзгәртеп кору һәм ябу;

4) хокукый һәм физик затларның янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүләрен тикшереп торуны оештыру;

5) янгыннан саклану буенча ирекле җәмәгать берләшмәләренең эшчәнлегенә ярдәм итү.

3. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә җирле программалар кабул итү;

2) хокукый затларның, җирле бюджетларның дифференциацияле түләү исәбеннән, гражданнарның ирекле иганәләреннән җирле үзидарә органнары каршында янгыннан саклану бүлекчәләрен оештыру;

3) җирле үзидарә органнары каршында янгын куркынычсызлыгын һәм янгыннан саклануны тәэмин итү өчен җирле салымнар һәм җыемнар билгеләү;

4) хокукый һәм физик затларның янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүләрен тикшереп тору;

5) гражданнарны янгын куркынычсызлыгы гамәлләренә өйрәтүне оештыру;

6) янгыннан саклану буенча ирекле җәмәгать берләшмәләре эшчәнлегенә ярдәм итү".

<u>9 статья.</u> 7 статьяда:

статьяның исемен түбәндәгечә бәян итәргә:

"7 статья. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә урындагы затларның хокуклары һәм бурычлары":

1 һәм 2 пунктларда "министрлыклар" сүзеннән соң ", дәүләт комитетлары" дип өстәргә, ә "учреждениеләр" сүзеннән соң "һәм" дип өстәргә, "колхозлар һәм совхозлар" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

2 пунктның 1 өлешендәге "икътисад тармаклары," һәм "милек

96



рәвешләренә карамастан" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

2 пунктның 2 пунктчасындагы "кешеләрне" сүзен "гражданнарны" сүзенә алмаштырырга;

2 пунктның 4 өлешендәге "күрсәтмәләрне үтәргә" дигән сүзләрдән соң "янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәргә" дигән сүзләр өстәргә;

2 пунктның 5 өлешендәге "хезмәткәрләрне" сүзеннән соң "һәм" бәйлеген өстәргә, "һәм колхозчыларны" сүзен төшереп калдырырга;

2 пунктка түбәндәге эчтәлектә 9 өлешне өстәргә:

"9) Татарстан Республикасының Янгынга каршы дәүләт хезмәте таләбе буенча үзләренә буйсынучы объектларның янгын куркынычсызлыгының халәте турындагы, шул исәптән алар җитештерә торган продукциянең янгын куркынычсызлыгы дәрәҗәсе хакындагы, шулай ук булып үткән янгыннар һәм аларның нәтиҗәләре турында белешмәләр һәм документлар бирергә".

<u>10 статья.</u> Законның 8 статьясын төшереп калдырырга.

<u>11 статья.</u> 9 статьяда:

статьяның 1 пунктындагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе гражданнары, республика территориясендә булучы чит ил гражданнары, гражданлыксыз затлар хокуклары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:";

1 пунктның 4 өлешендәге "(берләшмәләре)" дигән сүзне төшереп калдырырга;

1 пункттагы "Зыянны кире кайтару ирекле рәвештә яисә суд карары нигезендә башкарыла" дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

2 пунктның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) җитештерүдә һәм көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәргә";

2 пунктның 2 өлешендәге "мөмкинлеген" сүзеннән соң "законнарда билгеләнгән тәртиптә" дигән сүзләр өстәргә;

статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлектә 4 өлеш өстәргә:

"4) Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең урындагы затлары күрсәтмәләрен, карарларын һәм башка төрле законлы таләпләрен үтәргә".

3 пунктта "Татарстан торак-коммуналь хуҗалыгы берләшмәсе, шулай ук балансында торак фонды булган министрлыклар һәм ведомстволар тарафыннан" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

12 статья. 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10 статья. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге хокукларны яклауның гарантияләре

Хокукый һәм физик затларның әлеге Законның 7,9 статьяларында күрсәтелгән хокукларын кысучы дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары һәм аларның урындагы затлары карарлары, шулай ук гамәлләре хакында законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм чорда югарырак органнарга яисә судка шикаять белдерелергә мөмкин".

13 статья. 3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3 бүлек. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү".

14 статья. 11 статьяда:

1 пунктта "төзү өчен җавап бирергә" дигән сүзләрне "тәэмин итәргә" дип алмаштырырга, "кешеләрне" сүзләрен - "гражданнарны" сүзләре белән, "мәдәни-көнкүреш" сүзләрен "җәмгыяви-мәдәни һәм көнкүреш" сүзләре белән алмаштырырга;

2 пунктта "һәм Дәүләтнең янгыннан саклануны күзәтү хезмәте тарафыннан һичшиксез каралырга" дигән сүзләрне төшереп калдырырга һәм азакта "бу очракта Дәүләтнең янгыннан саклануны күзәтү хезмәте проект һәм норматив-техник документларга экспертиза үткәрергә, аларны килештерергә" дигән сүзләр өстәргә.

3 пунктның беренче абзацында "корылмалар өстәп төзү" сүзләреннән соң "төзү һәм" дип өстәргә;

4 пункттагы "(берләшмәләр)" сүзен ттөшереп калдырырга.

15 статья. 12 статьяда:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"12 статья. Торак пунктлары территорияләрен һәм предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар территорияләрен тоту";

статьяның 1 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

"1. Торак пунктларының территорияләре, шулай ук предприя-

тиеләр, учреждениеләр һәм оешмаларның территорияләре янгын куркынычсызлыгы нормалары һәм кагыйдәләренә туры китереп тотылырга тиеш".

2 пунктта "билгеләнә" сүзеннән алда түбәндәгечә бәян итәргә: "дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан".

16 статья. 13 статьяда:

1 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

"1. Гражданнар яшәү өчен билгеләнгән биналар гражданнарның иминлеген, аларны үз вакытында эвакуацияләүне тәэмин итүче; техник чараларны төзек хәлдә тоту, утның һәм яну продуктларының таралуын киметүче планлы һәм конструктив чишелешләргә җавап бирергә тиеш";

2 пунктта "администрация" сүзен "яллап бирүче" сүзенә, ә "фатир тотучылар" сүзләрен "яллаучылар, торак бина хуҗалары" сүзләренә алмаштырырга.

3 пунктта "(берләшмәләр)" сүзен төшереп калдырырга.

17 статья. 14 статьяда:

Статьяның исемен түбәндәгечә бәян итәргә:

"14 статья. Җитештерү һәм җәмгать биналарыннан, урыннарыннан, корылмаларыннан, җиһазларыннан һәм транспорт чараларыннан файдалану".

Статьяның 2 пунктында "берләшмәләр" дигән сүзне төшереп калдырырга, "корылмалардан" дигән сүздән соң "җиһазлардан" дигән сүз өстәргә.

18 статья. 16 статьяда "хәрәкәт итүче" сүзләрен төшереп калдырырга.

19 статья. 17 статьяда:

статьяның исемендә һәм 1 пунктта "икътисад өлкәләрен" сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта "икътисад өлкәләрендә" сүзләрен "җитештерүдә" сүзе белән алмаштырырга;

3 пунтта "(берләшмәләр)" сүзен төшереп калдырырга.

20 статья. 18 статьяда:

1 пунктта "(берләшмәләрне)" сүзен төшереп калдырырга;

2 пункттагы "фәнни-техник прогрессның хәзерге дәрәҗәсен исәпкә алып" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

21 статья. 19 статьяда 1 өлешне түбәндәгечә бәян итәргә:

"1) мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрендә тәрбияләү, белем бирү учреждениеләрендә (гомуми башлангыч, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирү) өйрәнү, башлангыч һөнәри, урта һөнәри, югары һөнәри һәм югары уку йортыннан соң белем бирү, белгечләрне яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү барышында уку программасына янгын куркынычсызлыгы курсын кертү юлы белән".

22 статья. Законны түбәндәге эчтәлекле 19' һәм 19'' статьялары белән тулыландырырга:

19' статья. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә мәгълүмати тәэмин ителеш.

Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә мәгълүмати тәэмин ителеш куелган бурычларны үтәү өчен кирәк булган махсус мәгълүмат системалары һәм мәгълүматлар банкы (моннан соң - мәгълүмат системалары) булдыру һәм алардан файдалану юлы белән тәэмин ителә.

Мәгълүмати системага янгын куркынычсызлыгы турында мәгълүматлар кертү нигезләре һәм тәртибе, шулай ук алар белән урындагы затларны һәм гражданнарны таныштыру шартлары һәм тәртибе Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган янгын куркынычсызлыгы буенча законнар һәм норматив документлар тарафыннан урнаштырыла.

Татарстан Республикасының Гражданлык оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү буенча дәүләт комитеты, метеорология хезмәтләре һәм дәүләтнең башка вәкаләтле органнары янгын куркынычсызлыгы өчен кулай булмаган хәлләр һәм фаразлар турында Дәүләт янгын куркынычсызлыгы хезмәтенә мәгълүматны кичекмәстән һәм түләүсез бирергә тиешләр.

Дәүләт янгын куркынычсызлыгы хезмәте таләбе буенча массакүләм мәгълүмат чаралары янгын куркынычсызлыгы мәсьәләләре турында мәгълүматны игълан итәргә тиешләр.

Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча кабул иткән карарлары турында халыкка мәгълүмат бирергә һәм янгын-техник белемнәрне таратуда ярдәм итәргә тиешләр.

19``. Янгынга каршы иминләштерү

Янгынга каршы иминләштерү ирекле һәм мәҗбүри рәвешләрдә тормышка ашырыла".

<u>23 статья.</u> Законның 4 бүлеге исемен түбәндәгечә бәян итәргә:

**"4 бүлек. Янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозган өчен җаваплылык"**

<u>24 статья.</u> 20 һәм 21 статьяларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"20 статья. Янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәмәгән яки бозган өчен җаваплылык йөкләү

Янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәмәгән яки бозган өчен, законнарга туры китереп, түбәндәге затлар җавап бирә:

- мөлкәткә ия, аннан файдаланырга яки эш алып барырга вәкаләтле затлар, шул санда җитәкчеләр;
- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен тиешле тәртиптә җаваплы итеп билгеләнгән затлар;
- үз вәкаләтләре чикләрендә эш урынындагы затлар;
- милекчеләр.

Республика һәм коммуналь торак фонды, җирле үзидарә торак фонды, шулай ук торак-төзелеш кооперативлар торак биналарында янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәмәгән яки бозган өчен җаваплылык фатир биләүчеләргә, ә шәхси милек булган торак өйләрдә, ишегалды корылмаларында, дачаларда, бакча йортларында аларның хуҗаларына йөкләнә.

21 статья. Янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәмәгән яки бозган өчен җаваплылык

Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарга туры китереп, хокукый һәм физик затлар:

- янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәмәгән яки бозган;

- Дәүләт янгын күзәтчелегенең предприятие, җитештерү участогы, агрегат эшен яки бина, корылма, җиһаз, урыннарны куллануны туктатып тору (тыю) турындагы күрсәтмә, карарларын үтәмәгән;

- лицензиясез эш алып барган яки Дәүләт янгын күзәтүе лицензиясе шартларын бозган;

- янгын куркынычсызлыгы нормаларына һәм кагыйдәләренә туры килүләре хакында Дәүләт янгын күзәтүе органнарының бәяләмәсе булмый торып, төзелеш, торак йортлар, биналар һәм мәдәни-көнкүреш, торак-коммуналь максатлардагы корылмалар, сәнәгать һәм башка предприятиеләр (файдалануга кертелүче комплекслар) төзегән һәм файдалануга биргән өчен дисциплинар, административ һәм җинаять җаваплылыгына тартылалар.

<u>25 статья</u>. 22 статьядагы 1 пунктта "кагыйдәләрен" сүзе "таләпләрен" сүзенә алмаштырыла, ә "яки үтәмәгәндә", "(берләшмәләрне)" һәм "гамәлдәге" сүзләрен төшереп калдырырга;

Статьяның 2 пунктында "(берләшмәләрне)" сүзен төшереп калдырырга, "янгын куркынычсызлыгы" сүзләреннән соң "шулай ук һәм" сүзләре өстәлә.

<u>26 статья.</u> 23 һәм 30 статьялардагы "минималь хезмәт хакы" дигән сүзләрне "хезмәт өчен түләүнең минималь күләме" дигән сүзләргә алмаштырырга.

<u>27 статья.</u> 23 статьяның 1 пунктындагы беренче абзацны түбәндәгечә бәян итәргә:

"1. Биналарда, корылмаларда, йортларда һәм алар тирәсендәге территорияләрдә, автотранспорт чараларында янгын куркынычсызлыгы стандартларын, нормаларын һәм кагыйдәләрен бозган яисә үтәмәгән өчен, Дәүләт янгын күзәтүенең лицензиясе булмаган килеш, эшчәнлек алып барган яки лицензия шартларын бозган өчен, Дәүләт янгын күзәтүе органнарының янгын куркынычсызлыгы нормаларына һәм кагыйдәләренә туры килү-килмәү хакында бәяләмәсе булмаган килеш, төзелеш өчен җир кишәрлекләре биргән, торак йортлар, биналар һәм мәдәни көнкүреш корылмалары, торак-коммуналь корылмалары, сәнәгать предприятиеләре һәм башка предприятиеләр (файдалануга кертү комплекслары) һәм корылма-

ры төзегән һәм аларны файдалануга тапшырган өчен, шулай ук проектлаштырганда һәм төзегәндә төзелеш нормаларының һәм кагыйдәләренең янгынга каршы таләпләрен бозган өчен, - ";

статья текстында "(берләшмәләр)" сүзләрен төшереп калдырырга.

28 статья. 24 статьяны төшереп калдырырга.

29 статья. 25 статьяны түбәндәгечә бәян итәргә:

"25 статья. Янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозу аркасында китерелгән зыянны кире кайтару

Хокукый һәм физик затлар янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозу аркасында китерелгән зыянны законнарда билгеләнгән тәртиптә кире кайтарырга тиешләр.

Хокукый затларны үз гаепләре аркасында китерелгән зыянны кире кайтару белән бәйле чыгымнарга дучар итүче урындагы затлар һәм башка хезмәткәрләр билгеләнгән тәртиптә матди җавапка тартылалар.

30 статья. 26 статьяда:

2 пунктның 2 өлешен түбәндәгечә бәян итәргә:

"2. Торак пунктларында һәм объектларда янгыннарны сүндерү һәм шуларга бәйле рәвештә һәлакәттән коткаруның беренчел эшләрен башкару".

31 статья. 29 статьяда:

1 пунктта "әлеге Законны һәм" сүзләрен төшереп калдырырга, "норматив" сүзеннән соң "хокукый" сүзен өстәргә;

2 пунктның беренче җөмләсендә "билгеләнгән" сүзен "йөкләнгән" сүзе белән алмаштырырга;

2 пунктның 1 өлешендә "министрлыклар" сүзеннән соң "дәүләт комитетлары" сүзләре өстәргә, "(берләшмәләр)" сүзен төшереп калдырырга, "кешеләрне" сүзен "гражданнарга" сүзе белән алмаштырырга.

2 пунктның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5) төзелеш мәйданнарын (трассаларын) сайлап алу буенча комиссияләрнең, шулай ук төзелеп беткән (үзгәртеп төзелгән)

объектларны кабул итү комиссияләренең эшендә хәлиткеч тавыш хокукы белән катнаша";

2 пунктның 6 өлешендә "кагыйдәләрен" дигән сүзне "таләпләрен" сүзе белән алмаштырырга.

2 пунктның 8 өлешендә "халык" һәм "масса төсендәге һөнәр" сүзләрен төшереп калдырырга, "эшче һәм хезмәткәрләр" сүзләрен "хезмәтчәннәр" сүзе белән алмаштырырга;

2 пунктның 10 өлешендә "фирмалары" дигән сүзне "оешмалары" дигән сүз белән алмаштырырга.

2 пунктның 11 өлешенә "хуҗалык исәбендәге" сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктның 12 өлешендә "министрлыклар тарафыннан" сүзләреннән соң "дәүләт комитетлары" сүзләрен өстәргә;

2 пунктның 13 өлешендә "янгыннан саклану хезмәтен нәтиҗәле оештыру" дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 14 өлешне өстәргә:

"14) хокукый һәм физик затларга янгын куркынычсызлыгы таләпләренең бозылуларын бетерү, товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә туры килмәүче товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) җитештерүдән төшереп калдыру, аларны чыгаруны туктату һәм сатуны туктатып тору, янгын чыгарлык хәлдә булган объекттан, бинадан, йорттан, агрегатлардан файдалануны туктатып тору буенча һичшиксез үтәлергә тиешле күрсәтмәләр, карарлар бирә".

<u>32 статья.</u> 30 статьяда:

1 пунктның икенче абзасында "Премьер-министр" сүзен "Министрлар кабинеты" дигән сүзләр белән алмаштырырга;

1 пунктның дүртенче һәм бишенче абзацлары урынына түбәндәге эчтәлекле яңа абзац язарга:

"Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең дәүләт янгын күзәтүен гамәлгә ашыру буенча шәхси состав билгән урыннар һәм вазыйфалар исемлеген Татарстан Республикасы янгын күзәтүе буенча дәүләт баш инспекторы билгели".

2 пунктның 1 өлешен түбәндәгечә бәян итәргә:

"1. Проект карарларының янгынга каршы норма һәм кагыйдәләргә туры килүе турында, шулай ук норма һәм кагыйдәләр булма-

ган тәэелеш объектларына проект карарлары буенча нигеэләмәләр бирергә";

2 пунктның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) янгын чыгарлык хәлдә булган предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның эшен туктатып торырга яисә тыярга, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә туры килмәүче продукция җитештерүне, төэүне, үзгәртеп коруны, икътисад һәм торак өлкәләре объектларын яңа җайланмалар белән тәэмин итүне, аерым төр эшләр, хеэмәт күрсәтүләр башкаруны тыярга";

2 пунктның 4 өлешендә "21 статьясында" дигән сүэләрне "23 статьясында" дигән сүэләр белән алмаштырырга;

3 пунктның беренче абзацында "һәм аның урынбасарлары"дигән сүэләрне төшереп калдырырга;

3 пунктның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"янгын чыгарлык хәлдә булган предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның эшен, шулай ук янгын куркынычсызлыгы таләпләренә туры килмәүче төэелешне, үзгәртеп коруны, икътисад һәм торак өлкәләре объектларын яңа җайланмалар белән тәэмин итүне, аерым төр эшләрне, хеэмәт күрсәтүләрне өлешчә туктатып торырга;"

3 пунктның 2 өлешен түбәндәгечә бәян итәргә:

"2) җирле проект оешмалары тарафыннан проект карарлары эшләгәндә аларның гамәлдәге нормаларга һәм кагыйдәләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирергә;

3 пунктның 3 өлешендә "21 статьясында" дигән сүэләрне "23 статьясында" дип үзгәртергә, ә "Дәүләтнең янгын күзәтүе органнары исеменнән" дигән сүэләрне төшереп калдырырга.

4 пунктның 2 өлешендә "21 статьясында" дигән сүэләрне "23 статьясында" дип үзгәртергә;

5 пунктның 1 өлешендә "янгын куркынычсызлыгы буенча норматив актларны" дигән сүэләрне "янгын куркынычсызлыгы таләпләрен" дигән сүэләргә алмаштырырга, "(берләшмәләрне)" сүэен төшереп калдырырга;

5 пунктның 3 өлешендә "документлар" сүэеннән соң "һәм" теркәгечен өстәргә, "(берләшмәләрне)", "колхоэларны, совхоэларны" сүэләрен төшереп калдырырга;

5 пунктның 4 өлешендә "шәһәр (район) прокуроры санкцияләре нигеэендә" сүэләрен "закон тарафыннан урнаштырылган тәртип-

тә" дигән сүзләр белән алмаштырырга, "тулай тораклардан һәм кунакханәләрдән кала," дигән сүзләрне төшереп калдырырга "фатир тотучылар" дигән сүзләрне "ялланучылар" сүзенә, "биләүчеләр" сүзен "милекчеләр" сүзенә алмаштырырга.

33 статья. 31 статьяның эчтәлеген түбәндәгечә бәян итәргә:

"Дәүләт янгын куәтүенең урындагы затлары закон нигезендә түбәндәгеләр өчен җаваплы булалар:

- янгын турындагы һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозу турындагы эшләр буенча тикшерү һәм алдан сорашу уздырганда, шулай ук Дәүләт янгын куәтүе органнарына бирелгән хокуклардан файдаланганда административ һәм җинаять-процессуаль законнарны үтәмәгән өчен;

- проектлаштыру документларының, яңа төзелешләрнең, биналарның һәм корылмаларның нормаларында һәм кагыйдәләрендә каралган янгынга каршы гамәлдәге таләпләрнең туры килү-килмәве өлешендә квалификациясез экспертиза уздырган өчен;

- Дәүләт янгын куәтүенең бәяләмәләрен һәм күрсәтмәләрен вакытында әзерләмәгән яисә начар сыйфатлы итеп әзерләгән өчен".

34 статья. 32 статьяны түбәндәгечә бәян итәргә:

"32 статья. Дәүләт янгын куәтүе органнарының урындагы затлары гамәлләренә шикаять белдерү

1. Административ җәза бирү турындагы карар хакында шикаять югарырак урындагы затка яисә судка бирелергә мөмкин, аларның хөкем карары катгый була.

2. Дәүләт янгын куәтүенең урындагы затлары гамәлләре (эш итмәүләре) турындагы шикаятьләрне һәм гаризаларны карау законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда башкарыла.

Шикаять белдерү шикаять белдерелгән карарны яисә гамәлне үтәүне туктатып тормый".

35 статья. 33 статьяның 2 өлешендә, "бу Закон нигезендә эшләнүче" дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

3 өлешендә "(берләшмәләр)", "милек рәвешләренә, нинди ведомствога буйсынуларына һәм шөгыльләренең төрләренә карамастан" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

36 статья. Законның 6 бүлеге исемен түбәндәгечә бәян итәргә:

**"6 бүлек. Янгыннан саклау хезмәткәрләрен һәм эшчеләрен, шулай ук гражданнарны хокукый һәм җәмгыяви яклау гарантияләре"**

37 статья. 36 статьяда 1 пунктның беренче абзацын түбәндәгечә бәян итәргә:

"1. Янгын сүндергәндә турыдан-туры җитәкчелек итү янгын сүндерү җитәкчесе - янгыннан саклану хезмәтенең янгын чыккан урынга килгән өлкән оператив урындагы заты тарафыннан гамәлгә ашырыла (әгәр башкасы каралмаган булса). Янгын сүндерү җитәкчесе башлык була, аңа янгын яисә һәлакәт урынындагы барлык көчләр һәм чаралар да буйсына".

1 пунктның өченче абзацындагы "(берләшмәләре)" дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

2 пунктның 1 өлешендәге "милек рәвешләренә, нинди ведомствога буйсынуларына һәм шөгыльләренең төрләренә карамастан" дигән сүзләрне "предприятиеләрне, учреждениеләрне һәм оешмаларны" дигән сүзләр белән алмаштырырга;

3 пунктның беренче абзацындагы "(берләшмәләр)" сүзен төшереп калдырырга, "кешеләрне" дигән сүзне "гражданнарны" дип үзгәртергә;

3 пунктның 2 абзацын түбәндәгечә бәян итәргә:

"Кешеләрне, янгын сүндерү чараларын, техниканы һәм җайланмаларны җәлеп итү тәртибен җирле хакимият билгели".

38 статья. 37 (2 пунктның 3 өлешендә), 39 (1 өлешендә), 43 (1 пунктның 9 өлешендә), 44,45 (икенче өлеше) статьялардагы "гамәлдәге" дигән сүзне төшереп калдырырга.

39 статья. 37 статьяда:

Статьяның атамасында "хезмәткәрләренең" дигән сүздән соң ""һәм эшчеләренең" дип өстәргә;

1 пунктның 1 абзацындагы "хезмәткәрләре" дигән сүздән соң "һәм эшчеләре" дип өстәргә;

1 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Янгыннан саклану хезмәте хезмәткәрләрен һәм эшчеләрен әлеге Законда янгыннан саклану хезмәтенә йөкләнмәгән вазыйфаларны һәм эшләрне үтәү өчен мәҗбүр итәргә беркемнең дә хакы юк".

2 пунктның беренче абзацында "хезмәткәрләре" дигән сүздән соң "һәм эшчеләре" дип өстәргә;

2 пунктның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

"Янгын сүндерүдән күрелгән матди зыян законнарда билгеләнгән тәртиптә кире кайтарыла. Янгыннан саклану хезмәтенең иң кыен шартларда эш иткән шәхси составы һәм янгын сүндерүдә башка катнашучылар китерелгән зыянны кире кайтарудан азат ителәләр";

2 пунктның 3 өлешендәге "(берләшмәләре)" сүзен төшереп калдырырга.

<u>40 статья.</u> 38 статьяда:

беренче өлешне төшереп калдырырга;

38 статьяның өченче өлешен түбәндәгечә бәян итәргә:

"Ирекле янгын сүндерүчеләрнең ирекле янгын сагы эшендә катнашуга бәйле матди кызыксындыруның барлык төрләренә дә салым салынмый".

<u>41 статья.</u> 40 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"40 статья. Янгынга каршы дәүләт хезмәте хезмәткәрләренә бирелүче ташламалар.

Янгынга каршы дәүләт хезмәте хезмәткәрләре һәм эшчеләре Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда билгеләнгән ташламалардан файдаланалар.

Янгынга каршы дәүләт хезмәте хезмәткәрләре үзләренең вазыйфаларын башкарганда - шәһәр, шәһәр яны, район транспортының һәм җирле транспортның (таксидан гайре) һәр төреннән, ә авыл җирендә юлында очраган транспорттан бушлай файдаланалар.

Янгын сүндерергә, һәлакәтләр, афәтләрдән килгән зыяннарны төзәтергә яисә аларны тикшерергә баручы Янгынга каршы дәүләт хезмәте хезмәткәрләре һава, тимер юл, елга һәм автомобиль транспортының шәһәрара рейсларына чиратсыз билет алырга хаклы.

Эшендә шәхси транспортыннан файдаланган хезмәткәрләргә билгеләнгән күләмдә акчалата компенсация түләнә".

42 статья. 41 статьяның икенче өлешендәге "җирле үзидарә органнары" дигән сүзләрне "дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары" сүзләре белән алмаштырырга.

43 статья. 42 статьяны төшереп калдырырга.

44 статья. 43 статьяда:

43 статьяның исемен түбәндәгечә бәян итәргә:

"43 статья. Янгынга каршы дәүләт хезмәте эшчәнлеген финанслау һәм матди-техник яктан тәэмин итү";

1 пунктның 1 өлешен "Татарстан Республикасының республика бюджетыннан" дип язарга;

1 пунктның 4 һәм 5 өлешләрендә "(берләшмәләре)" сүзен төшереп калдырырга;

1 пунктның 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6) бюджет хисабына һәм хуҗалык ысулындагы предприятиеләр төзи торган торак һәм җәмгыяви-мәдәни көнкүреш объектлары хисабына финанслнучы эшләрдән гайре, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, объектларны төзү, төзекләндерү, үзгәртеп тору, предприятиеләрне, биналарны, корылмаларны һәм башка объектларны киңәйтү, техник җиһазландыру эшләренең гомуми смета хакыннан 0.5 проценты күләмендә түләүләрнең норматив коэффициентлары";

1 пунктның 7 өлешен түбәндәгечә бәян итәргә:

"7) иминлек оешмаларының янгыннан саклану иминлеге буенча кергән иминлек кертемнәре суммасының кимендә биш проценты күләмендә мәҗбүри түләүләре";

3 пунктның беренче абзацындагы "җирле үзидарә органнары" дигән сүзләрне "дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары" сүзләре белән алмаштырырга;

статьяга түбәндәге эчтәлектәге 4 пунктны өстәргә:

"4. Янгынга каршы дәүләт хезмәтен матди-техник яктан тәэмин итү аның бүлекләрен финанслауга бүлеп бирелгән акчалар хисабына башкарыла.

Матди-техник яктан тәэмин итүнең тәртибен һәм нормаларын Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы билгели.

Янгынга каршы дәүләт хезмәте органнары һәм бүлекчәләре хокукый затлардан, шул исәптән чит илнекеләрдән дә, үзләренә

 108

йөкләнгән вазыйфаларны үтәү өчен кирәкле транспорт чараларын һәм башка техниканы законнарда билгеләнгән тәртиптә үз карамагына алырга хаклы.

Ведомстволы һәм ирекле янгыннан саклану хезмәтен матди-техник яктан тәэмин итү аларның милекчеләре тарафыннан гамәлгә ашырыла."

45 статья. Законга түбәндәге эчтәлектәге 43' статьяны өстәргә:

"43' статья. Янгыннан саклану хезмәтенең мөлкәте

Янгыннан саклану хезмәтенең мөлкәте үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәк булган күчемле һәм күчемсез мөлкәттән гыйбарәт.

Янгыннан саклану хезмәте мөлкәтенең максатчан билгеләнеше Янгынга каршы дәүләт хезмәте һәм дәүләт хакимиятенең тиешле башкарма органы ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, дәүләт хакимиятенең һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук Янгынга каршы дәүләт хезмәте бүлекчәләре төзелгән предприятиеләр янгыннан саклану хезмәтенә законнарда билгеләнгән тәртиптә элемтә чаралары белән җиһазландырылган биналар, корылмалар, эш урыннары һәм билгеләнгән нормалар нигезендә башка кирәкле мөлкәт тәкъдим итәләр".

46 статья. 44 һәм 45 статьяларда "(берләшмәләре)" сүзен төшереп калдырырга.

47 статья. 46 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Дәүләтнең янгын күзәтүе органнары таләбе буенча хокукый һәм физик затлар аларга янгын чыгу фактлары, зыяннарның, башка төрле зарарларның күләме турында мәгълүмат бирергә тиеш."

48 статья. 47 статьядагы "кешеләр" дигән сүзне "гражданнар" дигән сүз белән алмаштырыга.

49 статья. 48 статьяны түбәндәгечә бәян итәргә:

"48 статья. Хокукый затлар җитәкчеләренең янгыннарны

110

исәпкә алу өчен җаваплылыгы

Янгыннарны, янгын вакытында зарар күргән затларны һәм аларга килгән зыянны исәпкә алуның тулылыгы өчен, шулай ук бирелгән мәгълүматларның вакытында тәкъдим ителүе һәм дөреслеге өчен хокукый затлар законнар нигезендә җавап бирә".

50 статья. Әлеге Закон басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 31 гыйнваре
N 410